*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

# ТЫЛСЫМ+

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

№6 (53) март, 2023 нче ел

*Тәрбия ул – яхшы гадәтләргә өйрәтү.*
*Платон*



**Бу санда**


*Мөгаллимә вә остаз* 2

*Укытучыма!* 2

*Март! Яз башы, язның беренче ае* 3

*Нәүрүз - язны каршылау бәйрәме* 3

*Экология дәресе* 3

*Цифрлы дөньяда аралашу этикеты* 4

*Кечкенә дусларыбыз* 4


## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Гимназия - стажировка площадкасы



Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты тарафыннан тәкъдим ителеп, Мөслим районының Мөслим гимназиясе базасында Актаныш районының мәктәп директорлары өчен "Директорның креативлылыгы – идарә итүнең хәлиткеч факторы" дигән темага тәҗрибә уртаклашу (стажировка) форматында семинар үтте.

### Җиңү арты җиңү! Булдырасың, ИЛИНА!



14-18 мартта Орел шәһәрендә армрестлинг буенча РФ Беренчелеге узды. Ярышларда 707 спортчы катнашты. Мөслим гимназиясенең 10 нчы сыйныф укучысы Бариева Илина Россия чемпионы! Илинабыз “Россиянең спорт мастеры” нормативын үтәде!

"Экокалейдоскоп" экологик түгәрәгендә тәрбияләнүче Бариева Илина "Минем кече Ватаным: табигате, мәдәнияте һәм этносы" Бөтенроссия конкурсының региональ этабында экожурналистика номинациясендә катнашты һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы дипломына лаек булды. Котлыйбыз!

### “Кызыл, сары, яшел!” конкурсы



Гимназиянең актлар залында "Кызыл, сары, яшел" конкурсының муниципаль этабы узды. Конкурсның максаты: башлангыч мәктәп укучыларының Юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәнүгә кызыксынуын үстерү, балалар юл-транспорт травматизмын кисәтү. Мөслим гимназиясеннән 3 нче в сыйныфы укучылары өченче урынны алдылар. Сыйныф җитәкчеләре - Исмәгыйлова Гөлчәчәк Фирдәвис кызы.

### Театр яктылыкка, нурга илтә



10 нчы сыйныф укучылары Яр Чаллы шәһәрендә үткән, XV ачык Бөтенроссия “Пушкин укулары” иҗат конкурсында катнаштылар.

А.С. Пушкинның «Барышня – крестьянка» повестен сәхнәләштергән иҗат коллективы җинүче Дипломы белән бүләкләнде. Укучыларны, җитәкчеләре Хәйруллина Чулпан Алмазовнаны уңышлары белән котлыйбыз!

Гимназия яңалыклары - безнең рәсми сайтта https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym

Гимназия яңалыклары - социаль челтәрдә https://vk.com/gymnasiummus

# УКЫТУЧЫЛАР ҺӘМ ОСТАЗЛАР ЕЛЫ

2023 РОССИЯДӘ УКЫТУЧЫЛАР ҺӘМ ОСТАЗЛАР ЕЛЫ

*“Президентның 2023 елны Укытучы һәм остаз елы дип игълан итү турындагы карары әлеге һөнәр ияләренең җәмгыятьтә югары урын алып торуы, аларның мөһим эш алып барулары турында сөйли. Без укытучы һөнәренең абруе артуын күрәбез. Педагогик уку йортларына максатчан укучылар килә, яшь белгечләр зур кызыксыну белән укытучы эшенә алына, тәҗрибәле остазлар аларга һәрьяклап ярдәм итә, һөнәри бәйгеләр үткәрелә, педагогика өлкәсендә яңа йолдызлар кабына. Без укытучы һөнәре яңа дәрәҗәгә чыксын өчен үзебездән торганның барысын да эшлибез. Мәсәлән, хисапларны киметү буенча башлангычларны хуплыйбыз. Шулай ук берәр белгечкә үз мөмкинлекләрен төрле бәйгеләрдә ачарга мөмкинлек бирәбез. Укытучы һәм остаз елы кысаларында үтәчәк һәр чараның укытучы һөнәре абруен арттыруда мөһим роль уйнаячагында шигем юк”.*

***Сергей Кравцов***

## Мөгаллимә вә остаз

***Мөслим гимназиясенең укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Миңнегалиева Лилиана Расих кызы белән әңгәмә***

2023 нче ел “Укытучылар һәм остазлар елы” дип игълан ителде. Бу чакыру укытучы һөнәренең дәрәҗәсен арттыру һәм шушы һөнәргә күбрәк яшьләрне җәлеп итү максатын күз уңында тота.

Ә укытучы булу ул һөнәр генә дә түгел бит әле, ул – язмыш!

Килешле кыяфәтле, зәвыклы киенгән, әдәпле, әхлаклы тотышлы, ышанычлы адымнары белән туры карап алга баручы Укытучы образы турында күп язып була. Ә менә шул образны тормышта тулысынча ачкан, шул камиллекне үзендә туплаган укытучы һәм остазның үзе белән гаплэшеп алу тагын да мавыктыргычрак.

***Лилиана Расиховна, педагог булу бик зур җаваплылык бит, сездән меңләгән укучылар үрнәк ала. Укытучы булу сезнең өчен Нәрсәне аңлата?***

Укытучы - ул үз тәҗрибәсен һәм белемен тапшыручы кеше. Мин бик теләп дәресләр алып барам, балалар белән аралашам, бигрәк тә читкә юнәлтелгән темаларга, минем балалар белән яхшы мөнәсәбәтләрем бар һәм болар, барысы да катгый һәм таләпчән педагог булуга комачауламый.

***Бу һөнәрнең иң авыры нәрсәдә?***

Бу һөнәрнең иң кыены, дөресен генә әйткәндә, чиксез документлар һәм төрле кәгазьләр тутыру, алар күп вакыт таләп итә һәм балалар белән иҗади эштән читкә юнәлтә.

***Укытучы һәм остаз елыннанниләр көтәсез?***

Быелгы елга өметләр зүр.



***«Минем укытучым - минем үрнәгем» акциясе***

Укытучылар елы уңаеннан мәктәпләргә игътибар артсын иде. Киләчәк буынны әзерләүче – мәктәп, бала аңына “Ватан”, “Туган ил” төшенчәсен салырга тиеш. Соңгы вакыйгалар ул житешсезлекләрне танытты. Миңа калса, күп әйберләр үзгәрергә тиеш.

> ***“Яшь буынның киләчәге, аларның язмышы укытучы кулында, аның алтын йөрәгендә”.***

***Хәзер нигездә социаль челтәрләрдә күп утыралар... Социаль медиа хәзерге чынбарлыкның явызлыгымы? Сез анда бармы?***

Социаль медиа хәзерге дөньяда явызлык түгел. Бу, мөгаен, хәзерге дөньяның чынбарлыгы. Мин дә анда бар. WhatsApp, Сферум, ВК, Инстаграмда, чөнки дистанцион форматта аралашу кирәк.

***Лилиана Расиховна, ихлас әңгәмәгез өчен зур рәхмәт! Сезгә уңышлар, сәламәтлек телибез!***

***Әңгәмәдәш - Минһаҗева Диләрә***

## Укытучыма!

Татарстанның иң матур
Мөслим дигән авылында.
Гимназия бар икән бит,
Татарлар укый шунда.

Иң-иң булган һәм белемле
Балалар җыелганнар.
Ләйсән Габбассовна кебекләр
“Вундеркинд” чыгаралар.

Һәр дәрестә тактага,
Мәрданова Мәрьям Расил кызы.
Чык әле әйдә, дия,
4 нче а сыйныфында белем бирә
безгә.

Дәрестә ни генә өйрәнмибез,
Тырышабыз укырга.
Белемле һәм акыллы,
Без галимнәр булырга.

Гимназия җитәкчебез
Азат Фәрит улы да.
Алдынгы карашлы кеше,
Куша тырыш булырга.

Мәктәптән арып кайту юк,
Без көчле һәм терәкле.
Сәнгать мәктәбе дә көтә
Ачарга кирәк һәр сәләтне.

***Мәрданова Мәрьям, 4 нче а сыйныф укучысы***

## МАРТ! ЯЗ БАШЫ, ЯЗНЫҢ БЕРЕНЧЕ АЕ

***Кышның инде күз яшьләре тама,***
***Беткән димәк горурлыгы сүнеп.***
***Урамда яз әнә күкерәк кага,***
***Түбәләргә боз сөңгеләр элеп.***
***Бар тарафта кояш түккән балкыш,***
***Рәхимлелек сибә уңга-сулга,***
***Түбәләргә элгән бәллүрләрдә***
***Күз уларын алып җемелди, Март!***

Март! Яз башы, язның беренче ае. Яз белән әйтерсең, барлык тиреләк, яңадан яңара, табигать озакка талган йокысыннан, күкерәк тутырып сулыш алып күзен ача.

### ХАЛЫК СЫНАМЫШЛАРЫ

Мартта күк күкрәсә, салкыннар кетегез.

Март яңгырлы булса, гөмбәле җәйгә ишарә.

Мартта суык һәм коры булса, икмәк уңар.

Мартта боз сөңгеләре озын булса, яз озак килер.

Мартта томаннар еш төшсә, яңгырлы җәйгә.

Март ахырында карның тиз эрүе һәм суларның тиз китүе дә яңгырлы җәй билгесе.

### КӨНДӘЛЕК СЫНАМЫШЛАР

8 мартта кар төшсә, 8 апрельдә суык булыр. Әгәр бу көн коры икән, 8 апрельгә яңгыр көтегез.

9 мартта кар яуса, апрель дә шундый ук булыр.

10 мартта ала каргалар тавышланса, җәй яңгырлы килер. Әгәр кара каргалар оя корса, тиздән һава торышы утырыр.

11 март көнне җил көньяктан яки көньяк-көнбатыштан иссә – җылыта.

12 мартта – җылы яктан искән җил һәм тамчы таму – җылы җәйгә ишарә.

13 март көнне яңгыр яуса, җәй юеш килер. Түбәләрдә кар эри башласа, тиздән буран булыр.

14 март нинди – җәй шундый.

15 март көнне буран яки җил булса, яшел үләннәр баш төртүен тиз генә көтмәгез.

16 март көнне чыпчыклар түбә калайларына утырып, канатларын чистартса – җылы көннәр җитә.

17 март – кара каргалар элеккеге ояларына килсә, яз иртә килер, сулар тиз китәр.

18 март көнне ала каргалар төньякка карап ояласа һәм чаукылдашса – көннәр суыта.

19 мартта тукраннар тукылдаса, суыклар озак дәвам итә.

20 мартта кояш баеганда күк йөзе кызгылт төскә керсә, җил көчәя.

21 март көнне тургайлар килсә, яз килеп җитте диган сүз.

22 март җылы булса, 40 көн җылы торыр, бу көн суык булса, 40 көнгә сузылган суыклар көтегез.

23 март көнне ала карга томшыгын канат астына яшерсә, суыта.

24 мартта ала каргалар тавышланып йөрсә, һава торышы бозыла.

25 март көнне яңгыр яуса, арыш уңа. Ала каргалар җирдән яки кардан йөрсә, көннәр җылыта.

26 мартта кара каргалар кичен җыелышып, тавыш бирсә, алдагы атна җылы булыр.

27 мартта кар кояш җылысыннан эресә – уңышлы ел булыр, яңгыр явып эресә – корылык.

28 мартта акчарлаклар очып килсә, апрель җәй кебек булыр.

29 март нинди – апрель шундый.

30 мартта торналар килсә, кинәт җылыта. Гөрләвекләр ага башласа, ташулар да озак көттермәс.

31 март кичендә йолдызлар гадәттәгедән ваграк күренсә – яңгырга.

## НӘҮРҮЗ - ЯЗНЫ КАРШЫЛАУ БӘЙРӘМЕ

Әлек татарлар һәм башкортлар Яңа елны көн белән төн озынлыгы тигезләшкән 21 март көнне каршылый торган булганнар.

Яңа елны каршылау уңаеннан уздырыла торган бәйрәмнәр **Нәүрүз** дип аталган. Бу сүз безгә фарсы-таҗик телләреннән кергән һәм "яңа көн" диган мәгънәгә ия. Шул сәбәпле татарларда мартны "Нәүрүз ае" дип тә йөрткәннәр. Моның мәгънәсе «Яңа ел ае» дигәнгә туры килә.






Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында, Нәүрүз - язны каршылау бәйрәме гимназиядә дә үткәрелде. 5-7 нче сыйныф укучылары "Нәүрүз" бәйрәмен каршы алдылар. Квест формасында оештырылган ярышларда укучылар яз турында шигырьләр сөйләделәр, мәкальләр белү осталыкларын күрсәттеләр, табышмакларга җаваплар эзләделәр. Сыерчык оясы ясау, тупны кыршауга кертү буенча да ярыштылар. Җиңүчеләргә грамоталар тапшырылды.

## ЭКОЛОГИЯ ДӘРЕСЕ

Гимназиянең 5а, 6в, 8а сыйныфларында "Урман көче" диган темага Бөтенроссия экология дәресе үтте. Дәресне 10 сыйныф укучылары үткәрде.






# ЦИФРЛЫ ДӨНЬЯДА АРАЛАШУ ЭТИКЕТЫ



**Цифрлы этикет – цифрлы дөньяда кешеләр белән уңайсызлыклар тудырмыйча һәм үз чикләреңне саклап дөрес аралашу кагыйдәләре.**

Хәзер без югары технологияләр заманында яшибез, дөнья цифрлы мохиткә һәм реаль тормышка төптәгәл бүленә. Димәк, кешегә бүгенге көндә дөньяви этикет кагыйдәләре генә җитми: коммуникацияләрнең шактый өлеше Интернетта, мессенджерларда, телефон һәм башка гаджетларда уза, ә цифрлы дөнья үз этикетына ия.

**Төп кагыйдәләр:**

Әгәр дә тавышлы хат җибәрергә теләсәгез, башта әңгәмәдәшегездән: “Сиңа/сезгә тавышлы хатны тыңларга уңайлы буламы?” – дип сорагыз. Бәлки ул гомумән тавышлы хатларны яратмый һәм аңа аларны тыңлау уңайсыздыр. Шул ук принцип шалтыратуларга да кагыла;

Әгәр дә әңгәмәдәшегез сездән киңәш сорамаса, бер сәбәпсез тәнкыйтьләмәгез һәм киңәшләр бирмәгез. Гомумән, этикетның гына түгел,

*Көн кадагында*

ә бар коммуникация төзелешенең төп кагыйдәсе: киңәшне соралган чакта гына бирәбез;

Хәбәр җибәргәндә башта исәнләшәбез һәм аннан соң гына төп мәгълүматны язабыз;

Кешене рөхсәтсез чатларга кушмагыз;

Сөйләшкәндә бер фикерне бер хәбәргә сыйдырырга тырышыгыз, бер үк фикерне чагылдырган миллион хат – (= спам) кешенең вакытын һәм игътибарын хөрмәт итмәү билгесе.

Бу “кагыйдәләр” барысы да бер принципка - үзеңне һәм әңгәмәдәшеңне хөрмәт итүгә юнәлгән, чөнки нәкъ менә хөрмәт итә белу – цифрлы этикетның нигезе.

# КЕЧКЕНӘ ДУСЛАРЫБЫЗ

*4 нче б сыйныфы укучылары иҗаты*

## Мәчемнең исеме “Моня”

Кешеләрнең иң яхшы дуслары хайваннар икәнен һәркем белә. Кемгәдер этләр, кемгәдер мәчеләр ошый. Мин барысын да яратам, этем дә, мәчем дә бар. Мәчемнең исеме “Моня”. Ул гади генә песи түгел, хәйләкәр, шул ук вакытта акыллы да. Үзенчәлекләре дә бар: йоннары юк, зур озын колаклар, зур күзләр, бөдрә мыеклар, нәзек койрык һәм ябык озынча гәүдә. Сез минем мәченең токымы нинди икәнен аңлагансыздыр?

Без песиебезне бик яратабыз. Ул тычкан тота башлагач, тагын да күбрәк ярата башладык. Минемчә, песиләр дә, этләр кебек үк, кешеләрнең якын һәм тугры дуслары.

***Мирзаянова Әмирә***

***

Минем кечкенә дустым бар. Аның исеме “Барон”. Ул үзе кара гына төстә һәм сап-сары күзле. Шундый йомшак һәм бигрәк тә шаян!

Без мәктәпкә киткәч, ул өйдә бер үзе генә кала, йокысын туйдыра.

Барыбызны да сагынып көтеп тора, ишекне ачып керү белән мырлыймырлый аякка сырпалана. Әле ул көн саен тәрәзәгә менеп утыра да, рәхәтләнеп кошлар белән сөйләшә. Менә шундый шаян песием бар инде минем!

***Солтанова Аделина***

## Ак Барс

Өебездә, гаиләбезнең алтынчысы булып, яраткан песиебез яши. Без аңа ике апаем белән бергә “Ак Барс” дип исем куштык, чөнки аның йоны аксыл төстә. Үзе бик йомшак һәм елтырап тора. Песиебезнең күзләре дә бик матур. Песине күршеләрдән алдык, алганда ул бик кечкенә иде. Тиз арада зур булып үсте. “Ак Барс” без ашаган ризыкны ашамый. Тәмлетамак... Кибеттән алынган песи ризыгын гына ярата.

***Сәхбетдинов Тимур***

***

## Песиләрем

Минем бар песиләрем: “Фанни” һәм “Люцифер”. “Фанни”га ике яшь, ул бик тыныч, акыллы. “Люцифер”га бер яшь ярым. Бу песиебез тиктормас, чабуларга ярата.

Алар икесе бик дус, бергәләшеп уйныйлар, шаярышалар. “Люцифер”ның йоны бар, ә “Фанни” йонсыз, шәрә. Кышын тышта йөрсә туңа. Шуңа без аны кышын өйдә генә асрыйбыз.

***Могарова Айдинә***

***

## Песием

Минем песием “Бәхеткәй” исемле. Ул иртә белән генә өйгә керә, керү белән әбием янында



сырпалана. Аннан барыбызны да барлап чыга. Мине мәктәпкә озатып кала, койрыкларын болгый-болгый каршы ала. Мин “Бәхеткәй”не уйнатырга, ашатырга яратам. Ул әле тычкан-дошманнарны тотып безне шатландыра.

Кәефсез чагымда, песиемнең янымга килеп, койрыгын болгап, сырпалануы була, бөтен борчулар да онытыла. Песием юынырга бик ярата. Тәпиләре белән битен, колак артларын юа.

Мин бик шат, шундый песием булуына. Минемчә, һәр өйдә песи яшәргә тиештер. Аларның карап торулары, бездән наз, ярату көтүләре генә дә ни тора!

***Марданшина Инзилә***

ТЫЛСЫМ+
Март, 2023 нче ел
№6 (53)
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Миңнаҗева Камилә
**Корректорлар:** Миңнаҗева Диләрә
**Корреспондентлар:** Солтанова Алия, Айгельдина Зарина
**Дизайнер:** Садриев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Латыпов Илназ, Хаертдинов Ранис

*2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә*
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3) **Тираж:** 100